ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.08.2026 №63

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» 2017 елның 22 сентябрендәге 90 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» 2017 елның 22 сентябрендәге 90 номерлы карары (10 апрель, 2018 ел № 50, 03 август, 2018 ел N 97 карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары» 3 пунктының бишенче абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килү нәтиҗәсендә» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Башлык Р.Ф.Хисамутдинов